ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2019 г. Заинск № 689

**"2014-2019 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 11 мартындагы 471 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «2014-2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.11.2013 елның 22 ноябрендәге 910 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 13 июлендәге 575 номерлы карары, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2014 елның 14 мартындагы 355 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2014-2019 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 11 мартындагы 471 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 21 мартындагы 454 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) карар исемендә «2014 - 2019» саннарын «2014 - 2022» саннарына алмаштырырга;

2) 1 пунктта «2014 - 2019» саннарын «2014 - 2022» саннарына алмаштырырга;

3) күрсәтелгән карар белән расланган «2014 - 2019 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасында (алга таба - программа):

а) «2014 - 2019» саннарын «2014 - 2022» саннарына алмаштырырга;

б) программа паспортында:

«Программа исеме», «Программаны гамәлгә ашыру сроклары» юлларында «2014 - 2019» саннарын «2014 - 2022» саннарына алмаштырырга;

«Программаны финанслау күләмнәре» юлына түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«2020 елда – 170,1мең сум;

2021 елда – 170,1 мең сум;

2022 елда – 170,1 мең сум»

«Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре» юлында:

беренче абзацта «2019» санын «2022» санына алмаштырырга;

в) Программаның II бүлегендә:

ундүртенче абзацта:

«2014 -2019» саннарын «2014-2022» саннарына алмаштырырга;

г) Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаның чаралары Зәй муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. 2014-2022 елларга Программаны финанслау күләме 1662,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2014 елда – 226,8 мең сум;

2015 елда – 225,1 мең сум;

2016 елда– 190,1 мең сум;

2017 елда– 170,1 мең сум;

2018 елда– 170,1 мең сум;

2019 елда– 170,1 мең сум;

2020 елда– 170,1 мең сум;

2021 елда– 170,1 мең сум;

2022 елда– 170,1 мең сум.

"2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү" дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында гамәлгә ашырыла торган программа чаралары күрсәтелгән дәүләт программасында каралган ассигнованиеләр күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана.

Бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, программаны тормышка ашыруга җибәрелә торган акчаларның күләменә чираттагы финанс елына Зәй

муниципаль районы бюджеты проектын эшләгәндә ачыклык кертелә»;

д) Программаның V бүлегенең тугызынчы абзацында:

«2020» санын «2022» санына алмаштырырга;

е) Программага кушымта исемендә:

«2014-2019» саннарын «2014-2022» саннарына алмаштырырга;

«2014 елдан 2022 елга кадәр чорга» сүзләрен өстәргә;

Программага 1 һәм 2 кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

3. Башкарма комитетның оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Сергеева М.Г.
707090

"2014-2022 елларга
Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районында
муниципаль хезмәтне үстерү"
муниципаль программасына
1 нче кушымта»

**МАКСАТЧАН ФИНАНСЛАУНЫ ТАЛӘП ИТМИ ТОРГАН ОЕШТЫРУ ҺӘМ НОРМАТИВ-ХОКУКЫЙ ХАРАКТЕРДАГЫ "2014 - 2022 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТНЕ ҮСТЕРҮ" МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ ЧАРАЛАРЫ ҺӘМ АЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ**

| N п/п | Төп чараның исеме | Башкаручылар | Төп Чараларны үтәү срог | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторларның билгеләре | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2013 ел (база) | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| 1 максат: Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне башкаруның нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 нче бурыч: җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән аларның оештыру структурасын һәм штат санын камилләштерү аша | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1.1. | Җирле үзидарә органнары структурасына анализ ясау | Зәй муниципаль районы башкарма комитетының икътисад бүлеге | 2014 ел | Җирле үзидарә органнары структурасын һәм аларны камилләштерү тәкъдимнәрен анализлау нәтиҗәләре буенча хисап төзү | - | + | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.1.2. | Татарстан Республикасының Зәй муниципаль районында | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты | 2014, 2017 еллар | Муниципаль хезмәт үсешенең алдагы чорга муниципаль | - | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | муниципаль хезмәтне үстерүнең алдагы чорга муниципаль программасын эшләү һәм кабул итү | юристы, Зәй муниципаль районы җирле үзидарә органнары | | программаларын раслаган җирле үзидарә органнары өлеше, аларның гомуми күләмендә, процентларда | | | | | | | | | | |
| 1.1.3. | Муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт узуга бәйле таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны, шул исәптән коррупциягә каршы тору законнарын үтәвен тикшереп торуны гамәлгә ашыру | Зәй муниципаль районы Советының кадрлар эше буенча белгече | 2014 - 2016 еллар | Үткәрелгән тикшерү чаралары һәм башка чаралар саны | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.1.4. | Муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләрен кертү | җирле үзидарә органнары | 2017 - 2022 еллар | Муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре турында җирле үзидарә органнарының ел саен актуальләштерелгән хокукый актлары булу | - | - | - | - | + | + | + | + | + | + |
| 1.1.5. | Җирле үзидарә органнары структурасы стандартын кертү | җирле үзидарә органнары | 2018 - 2020 еллар | Җирле үзидарә органнары структурасы стандартларына туры китерелгән | - | - | - | - | - | + | + | + | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | структуралар | | | | | | | | | | |
| 1.1.6. | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасында җирле үзидарә органнарының кадрлар бүлекчәләре хезмәткәрләренең кадрлар эшен алып баруны тәэмин итү | Зәй муниципаль районы Советының кадрлар эше буенча белгече | 2017 - 2022 еллар | Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасында җирле үзидарә органнарының кадрлар составын характерлаучы актуаль белешмәләр булу | - | - | - | - | + | + | + | + | + | + |
| 2 нче бурыч: муниципаль хезмәткәрләрне сайлап алуның, алар хезмәтен комплекслы бәяләүнең һәм аларны үстерүнең нәтиҗәле механизмнарын кертү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2.1. | Яңа кабул ителгән хезмәткәрләр һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен адаптация һәм остазлык системасын булдыру | Зәй муниципаль районы Советының кадрлар эше буенча белгече | 2014 ел | Яңа кабул ителгән муниципаль хезмәткәрләр өчен адаптацияне һәм остазлыкны җайга салучы норматив хокукый акт кабул итү | - | + | - | - | - | - | - | - | - | - |
| 1.2.2. | Муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук вакантлы муниципаль хезмәтне биләүгә дәгъва кылучы затларның һөнәри | Җирле үзидарә органнары | 2014гел | Муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы | - | + | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | белемнәрен һәм күнекмәләрен бәяләү ысулларын вакантлы муниципаль хезмәтне биләүгә, аттестацияләүгә, квалификация имтиханына, кадрлар резервын формалаштыруга конкурслар уздырганда камилләштерү | | | затларның һөнәри белемнәрен һәм күнекмәләрен бәяләү методикасын муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә, аттестацияләүгә, квалификация имтиханына, кадрлар резервын формалаштыруга конкурслар үткәргәндә кабул итү | | | | | | | | | | |
| 1.2.3. | Муниципаль хезмәткәрләрнең идарә компетенцияләрен бәяләүне уздыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру | Җирле үзидарә органнары | 2015, 2020, 2022 еллар | Муниципаль хезмәткәрләрнең идарә компетенцияләрен бәяләүне оештыру | - | - | + | - | - | - | - | + | - | + |
| 3 нче бурыч: Муниципаль хезмәттә мотивацияләүнең, стимуллаштыруның нәтиҗәле системасын төзү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.3.1. | Муниципаль хезмәттә классны чиннар бирү тәртибен камилләштерү | Зәй муниципаль районы Советының кадрлар эше буенча белгече | 2017 ел | Муниципаль хезмәттә классны чиннар бирү өлешендә законнарны камилләштерү буенча формалаштырылга | - | - | - | - | + | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | н тәкъдимнәр | | | | | | | | | | |
| 4 нче бурыч: муниципаль хезмәткә яшь, перспективалы белгечләрне җәлеп итү һәм эштә калдыру | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.4.1. | Публикация Массакүләм мәгълүмат чараларында, җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеге турында мәгълүматны бастырып чыгару | Җирле үзидарә органнары | 2014 - 2022 еллар | Муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеге, муниципаль хезмәтне үстерү турында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, җирле үзидарә органнары рәсми сайтларында урнаштырылган мәкаләләр һәм башка мәгълүмати-аналитик материаллар саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 |
| 5 нче бурыч: җәмәгать контроле системасын үстерү һәм граждан җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек, муниципаль хезмәттә коррупциягә каршы көрәш чараларын гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.5.1. | Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвачыларның аны үзуга бәйле таләпләрне һәм чикләүләрне үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру | Зәй муниципаль районы Советының кадрлар эше буенча белгече | 2017 - 2022 еллар | Тикшерү чараларын тормышка ашыру | - | - | - | + | + | + | + | + | + | + |
| 6нчы бурыч: муниципаль хезмәтне норматив һәм методик яктан тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.6.1. | Муниципаль хезмәт | Юридик бүлек, | 2017 - 2022 | Кадрлар эше | - | - | - | - | + | + | + | + | + | + |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | турындагы законнарның үтәлешенә анализ ясау, җирле үзидарә органнарында кадрлар эшен камилләштерү, персонал белән идарә итүнең заманча технологияләренә юнәлеш бирү | Зәй муниципаль районы Советының кадрлар эше буенча белгече | еллар | турында аналитик язма | | | | | | | | | | |

Приложение N 2
"2014 - 2022 елларга
Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районында
муниципаль хезмәтне үстерү"
муниципаль программасына
2 нче кушымта

"2014-20222 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТНЕ ҮСТЕРҮ "МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ ЧАРАЛАРЫНЫҢ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ, НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ ҺӘМ ФИНАНСЛАУ

| N п/п | Төп чараның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Значения индикаторов | | | | | | | | | | Финансирование за счет средств бюджета Республики Татарстан, тыс. рублей | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2013 ел (база елы) | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 |
| Максат 1: Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәүнең нәтиҗәлелеген арттыру | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1нче бурыч: Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең, шулай ук кадрлар резервына кертелгән затларның һөнәри һәм идарә компетентлыгын үстерү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1.1. | Муниципаль хезмәткәрләрнең һәм җирле үзидарә органнарындагы вазыйфалар | Зәй муниципаль районы Советының кадрлар эше буенча | 2014 - 2022 еллар | Тиешле елда квалификацияне күтәрүне узган муниципаль хезмәткә | 33 | 33 | 33 | 33 | 33 | 33 | 33 | 33 | 33 | 33 | 226,8 | 225,1 | 190,1 | 170,1 | 170,1 | 170,1 | 170,1 | 170,1 | 170,1 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ны биләүче, муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган хезмәткәрләрнең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүне, муниципаль хезмәткәрләрне һөнәри яктан яңадан әзерләүне оештыру | белгече | | рләр һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар өлеше, процентларда | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1.2. | Муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләр, җирле | Зәй муниципаль районы Советының кадрлар эше буенча белгече | 2019 - 2022 еллар | Мобилизацион әзерлек һәм дәүләт серен яклау мәсьәләләре буенча | - | - | - | - | - | - | + | + | + | + | - | - | - | - | - | 1 200 | 1 200 | 1 200 | 1 200 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | үзидарә органнарында вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләр, муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган хезмәткәрләр өчен мобилизация әзерлеге һәм дәүләт серен яклау мәсьәләләре буенча квалификацияне күтәрүне оештыру | | | укулар үткәрү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1.3. | Муниципаль районда формалаштырылган кадрлар резервына кертелгән затларны әзерләүне (укытуны, стажировканы) | Зәй муниципаль районы советының кадрлар эше буенча белгече | 2014 - 2022 еллар | Районда әзерлек (укыту, стажировка) үткән, кадрлар резервына кертелгән затларның гомуми | 10 | 40 | 70 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | оештыру | | | санында ЗМРда (үсә торган нәтиҗә) формалаша торган, кадрлар резервына керган затларның гомуми өлештә күләме, процентларда | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2 нче бурыч: Муниципаль хезмәттә мотивацияләүнең, стимуллаштыруның нәтиҗәле системасын төзү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2.1. | Сәламәтлеккә зыян килү очрагыннан муниципаль хезмәткәрләрне мәҗбүри дәүләт иминләштерүе системасына кертү | Җирле үзидарә органнары | 2019 ел | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган тәртиптә муниципаль хезмәткәренең | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | 195,1 | 159 | 159 | 159 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | сәламәтлегенә зыян килү очрагына мәҗбүри дәүләт иминиятен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына 2019 елда башка бюджетара трансфертлар бирү | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |